**Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм үсеше буенча педагогик эштә автор дидактик уеннарын куллану**

Балаларны үз ана телендә сөйләшергә, аралашырга өйрәтү, туган телебезне ярату, аңа карата ихтирам тәрбияләү бугенге көндә дә иң мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора.

Бала дөрес итеп сөйләшкәндә генә, әдәби тел нормаларын сөйләмдә кулланганда һәм сөйләмендә эзлеклелек булганда гына аның зиһене, логик фикерләү сәләте, игътибары, танып белү эшчәнлеге үсә. Безгә, педагогларга, баланың сөйләм телен үстерү өчен күп көч куярга туры килә. Баланың сөйләме нәтиҗәле баесын һәм сәнгатьле булсын өчен, мөмкин булган барлык ысулларны кулланырга кирәк.

Автор дидактик әсбапларын куллану балалар сөйләмен үстерүе буенча уңышлы метод булып тора.

Бу эштә миңа үземнең **"Әкияти өй"** дигән дидактик кулланмам ярдәмгә килә.

**Дидактик әсбап "Әкияти өй"** - бер яктан "Теремкәй", икенче яктан "Әкияти урман" формасында ясалды.

Рәсемнәрне урнаштыру өчен тәрәзәләр рәвешендә кесәләр куелган.

Теремкәйгә саннар-цифрлар урнаштырып, рәсемнәр куеп математика, логик фикерләүне үстерү буенча төрле биремнәр, күнегүләр үткәрергә мөмкин.

"Әкияти урман" ягына - татар халык әкиятләре һәм Идел буе халыклары әкиятләре буенча картиналар; әкият геройлары сурәтләре; лото уены өчен әкиятләрдән картиналар фрагментларын һәм рәсемнәрен урнаштырып, төрле уеннар, биремнәр, күнегүләр үткәрергә була.

**Максат:** балаларның сөйләм телен, бәйләнешле сөйләмне стерү. Татар халык һәм Идел буе халыклары әкиятләре турындагы белемнәрен ныгыту һәм актуальләштерү. Полифункциональ ярдәмлек кулланып, мәктәпкәчә яшьтәге балаларны төрле яктан үстерү.

**Бурычлар:**

- балаларның татар халык әкиятләре турында белемнәрен ныгыту һәм киңәйтү;

халык авыз иҗатына мәхәббәт тәрбияләү; хәтерне, фикерләүне, күзәтүчәнлекне, сөйләмне үстерү; үзара ярдәмләшү, иптәшлек; дуслык, уенда намуслылык, гаделлек кебек сыйфатлар тәрбияләү;

- балаларның сүз байлыгын арттыру;

- бәйләнешле сөйләм телен үстерү;

- әңгәмәне дәвам итү сәләтен ныгыту.

Дидактик кулланма 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балалар өчен, балаларның бәйләнешле сөйләмен үстерү буенча, балалар бакчасында дидактик уеннар өчен, балалар белән оештырылган белем эшчәнлегендә һәм режим вакытларында, шулай ук балаларның мөстәкыйль эшчәнлегендә кулланылырга мөмкин. Ярдәмлек балаларның сүзлек запасын тулыландыруга ярдәм итә, дөньяга карашны киңәйтә, Ватанга мәхәббәт һәм башка милләт халыкларына хөрмәт тәрбияли, балалар арасында дуслык мөнәсәбәтләрен үстерә, логик фикерләүне, игътибарны, хәтерне, төрле халыкларның традицияләренә һәм мәдәниятенә, театр-уен эшчәнлегенә кызыксынуны үстерә, кул бармакларының вак моторикасын, балаларның коммуникатив сәләтләрен, сенсор эталоннарын һәм эмоциональ өлкәсен үстерүгә ярдәм итә).

**Татар халык әкиятләре. Идел буе халыклары әкиятләре.**

**Уен вариантлары:**

1. *Дидактик уен «Бу нинди әкият?»*

2. *Дидактик уен «Рәсемнәрен тезеп әкиятне сөйлә»*

3. *Дидактик уен «Әкиятне бергә җый»* рәсемнәрне бергә җыярга.

4. *Дидактик уен «Парын тап»*

5. *Лото «Үз урынын тап»* Картинада фрагментларны табарга.

6. *Дидактик уен «Әкият геройлары»*

Балалар рәсемнәрне карыйлар һәм бу геройның нинди булуын һәм аның нинди әсәрдән булуын аңлаталар.

*7. Дидактик уен «Әкиятне искә төшер»*

Әкият геройларының рәсемнәрен күрсәтергә. Сораулар: Геройлар нинди әкияттән? Теремкәйне беренче кем тапкан? Икенче кем килде? Өченчесе? Соңгы булып кем килде һәм теремкәйне ватты?)

*8. Дидактик уен «Тавышыннан таны»*

Тавышның тембрын, сөйләмнең интонацион аңлаешлылыгын үстерү. Педагог әкият персонажларын сурәтли. Бала танырга тиеш. Аннары бала һәм педагог рольләрен алыштыралар.

**Бирем вариантлары:**

*9. «Табышмак әйтәм, җавабын тап»*

*10. «Бу өзек нинди әкияттән?»*

*11. «Кем тизрәк?» (Сораулар-җаваплар)*

*12. «Мин башлыйм, син дәвам ит»*

*13. Викторина «Әкиятләр буенча сәяхәт»*

*14. КВН «Яраткан әкиятләрем»*

*15. «Хаталарны тап» («Чукмар белән Тукмар»*

Балалар герой, персонажларның характерын, үз-үзен ничек тотышы турында сөйли, нинди әкияттән икәнлеген әйтә. Еш кына алар үзләре дә әкиятләрне үзләренчә дәвам итә, яки яңа әкиятләр иҗат итә алалар.

«Әкияти өй» дигән шушы кулланма ярдәмендә, әкиятләр буенча бирелгән биремнәр, уеннар балаларның сөйләм телләрен үстерүгә зур этәргеч ясый һәм зур ярдәм итә.

Кушымта №1



*Дидактик уен «Бу нинди әкият?»*



*Дидактик уен «Рәсемнәрен тезеп әкиятне сөйлә»*




*Лото «Үз урынын тап»*



*Җырлы-биюле уен «Әкият геройлары»*